Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

1 ноябрь 2019 ел N 2

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге Бишмунча авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә,

КАРАР БИРӘ:

1. 2019 елның 16 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Бишмунча авылының Совет урамы 1 -17,19,21,23,25,27 йортларында, Г.Тукай урамы 1 - 22 йортларында, Чишмә урамында яшәүчеләрнең үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Бишмунча авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Совет урамы, 10 нчы йорт.

2. 2019 елның 16 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Бишмунча авылының Совет урамы 18,20,22,24,26,28-42,43,45,47,49,51,53,55 йортларында, Чапаева урамы 1-13 йортларында яшәүчеләрнең үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Бишмунча авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Совет урамы, 34А йорты, “Чулпан” кибете.

3. 2019 елның 16 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Бишмунча авылының Совет урамы 44,46,48,50,52,54,56,58-66,68 йортларында, Г.Тукай урамы 22А-34 йортларында, Г.Газизов урамында,Чапаев урамы № 14-29 йортларында яшәүчеләрнең үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Бишмунча авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Совет урамы, 62А йорты, “Көндәлек товарлар кибете”.

4. 2019 елның 16 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Бишмунча авылының Совет урамы 67,69-84,86,88,90 йортларында, М.Җәлил урамында яшәүчеләрнең үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Бишмунча авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Совет урамы, 83 нче йорт, “Ирәч” кибете.

5. 2019 елның 16 ноябрендә 15 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Бишмунча авылының Совет урамы 85,87,89-135 йортларында, Нефтяниклар урамында яшәүчеләрнең үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын Татарстан Республикасы

Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Бишмунча авылында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Совет урамы, 107 нче йорт, “Ирәч” кибете.

6. 2019 елның 16 ноябрендә 16 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы Әлмәт районы Бишмунча авылының Яшьләр урамында яшәүчеләрнең үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының алтынчы этабын Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авылы мәдәният йорты бинасында түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Яшьләр урамы, 5 нче йорт, кв.1.

7. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Бишмунча авыл җирлегенең Бишмунча авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме: Бишмунча авылында урам утлары челтәрен норматив хәлгә китерүгә, сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрүгә түләү өчен тоту?”

«РИЗА» «КАРШЫ»

8. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлегенең Бишмунча авылында сайлау хокукына ия авыл халкының исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

9. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Бишмунча авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

10. Әлеге карарны җыен үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча, Бишмунча авылы территориясендә Совет урамы, 57А йортында урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Әлмәт муниципаль районы сайтының «Интернет» челтәрендә урнаштырырга (халыкка җиткерергә).

11. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткергән) көненнән үз көченә керә.

Бишмунча авыл
җирлеге башлыгы Р.Г.Фазлыев